**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Уразай авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Уразай авылы № 102 3 март 2015 ел.

Уразай авылы җирлеге биләмәсендә
узарасалым җыю һәм куллану
буенча, җирле референдум үткәрү
көнен билгеләү турында.

2002 елелнын 12 июнендә кабул ителгән "Россия Федерациясе гражданнарының референдумда катнашу һәм сайлау хокукларының төп гарантияләре" турындагы 67 номерлы Федераль законның 15 статьясы, 2003 елнын 06 октябрендә кабул ителгән "Россия Федерациясендә җирле узидарәне оештыруның уртак принциплары" турындагы 113 номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, 2004 елның 24 мартында кабул ителгән "Җирле референдум" турындагы 23 номерлы Татарстан Республикасы законы, Уразай авыл җирлеге Уставының 12 статьясы, Уразай авылы башкарма комитетынын 27 февраль 2015 елда чыккан 33 номерлы "Җирле референдум үткәрү" карары, Уразай авыл җирлеге Советынын 03 март 2015 елда чыккан 101 номерлы "Җирле референдум үткәрү" карары нигезләрендә,

Уразай авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Уразай авыл җирлеге биләмәсендә узарасалым җыю һәм куллану буенча 19 апрель 2015 ел көнне референдум үткәрергә.
2. Референдумда караласы мәсьәлә:
   "Сез, Уразай авыл җирлеге биләмәсендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 2015 елда 200 сум күләмендә узарасалым җыю белән килешәсезме. Узарасалым түләүдән көндезге якта укучы студентлар, I группа инвалидлар азат ителә. Узарасалымнан кергән керем түбәндәге юнәлештә тотыла:

-авыл җирлеге территориясен тозеклэндеру очен (урамнарны яктыртуны , территорияне яшеллэндеруне, урамнарга хэм йортларга урам исемнэре хэм йорт номерлары урнаштыруны, кечкенэ архитектура формалары кую хэм карап тотуны кертеп)

ӘЙЕ ЮК

3. Карар районнын "Маяк" газетасында бастырыла һәм Азнакай муниципаль районының Интернет челтәрендә http://aznakyevo.tatarstan.ru веб – адресы буенча урнаштырыла.
4. Карар газетада бастырылып чыккан көненнән көченә керә.

Председатель: А.М.Шарифуллина